ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

КӨЗГЕ

ФЕВРАЛЬ, 2017 нче ел

№6 (20)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**






**14—Гашыйклар көне**

**23— Ватанны саклаучылар көне**

23 нче февраль көнне илебез төп бәйрәмнәрнең берсе – Ватанны саклаучылар көнен билгеләп үтә. Ил барда – егет хур булмас, диләр, илебез сагында торучы кыю, курку белмәс егетләребез барында илебез халкы тыныч йоклар, күгебез гел аяз булыр. Хөрмәтле ир-атларыбыз! Барыгызны да Ватанны саклаучылар көне белән эчкерсез котлыйбыз! Сезгә һәм сезнең гаиләләргә тыныч күк йөзе, нык сәламәтлек, уңышлар һәм иртәгесе көнгә ышаныч телибез!

Сезгә һәрвакыт ихтыяр көче, гаилә бәхете юлдаш булсын! Тормыш сынауларына бирешмичә, һәрвакытта да чын ирләр булып калуыгызны телибез! ***Әтиләре, абыйлары үрнәгендә патриотик рухта тәрбияләнгән яшь егетләребезгә хәрби хезмәтләрен үтәгәндә, туган якта калган якыннарының тынычлыгын саклап, үзләрен яхшы яктан гына күрсәтерләр дигән ышаныч белдерәбез.***

**Гөлшат Гайсина**

## Бу санда:


| | |
|---|---|
| Сафта йөрү һәм җыр смотры | 2 |
| Батырлар онытылмый | 3 |
| Якыннан танышыйк! | 4 |
| Әниемә бүләк! | 5 |
| Әтиләр конференцясе | 6 |
| Парламент дәресләре | 6 |
| Котлыйбыз! | 7 |


**«Без бергә”** дип исемләнгән Республика конкурс – фестивале яңа талантлар ачты. 12 нче февраль көнне шул уңайдан мәктәбебездә концерт оештырылды. Укучылар татар халык фольклорының төрләре буенча чыгыш ясадылар.





## 20 нче февраль көнне мәктәбебездә <u>Сафта йөрү һәм җыр смотры</u> узды.






### 14 нче февраль—гашыйклар көне

Дөньяның матурлыгы саф хисләрдә чагылыш таба. Ә беренче саф хисләр мәктәп елларында бөреләнә.










Бәйрәмнән фоторепортаж







Гражданлык-патриотик тәрбия айлыгы кысаларында 21 февральдә **<u>“Җиңү вальсы”</u>** дигән хәрби җырлар конкурсы үтте. Конкурста барлык сыйныфлар да бик теләп катнаштылар. Башлангыч сыйныфлар арасында б еренче урынны 4 сыйныф укучылар ы ал са 2, 3 урыннарны III, II сыйныфлар бүлеште. Урта сыйныфлар арасында I урынны V, ә II, Ш урыннарны VI ,VII сыйныфлар яулады. Өлкән сыйныфлар арасында җиңүче итеп VIII сыйныф, II, Ш урынга IX , X сыйныф укучылары лаек булдылар.













# Якыннан танышыйк!





**Укучыларның сорауларына башлангыч сыйныф укытучысы Гомәрова Флүсә Фоат кызы җавап бирә.**

**- Глүсә Фоатовна, укытучы булу — балачак хыялымы яки үсә төшкәч барлыкка килгән теләкме?**

- Укытучы һөнәре иң хөрмәтле һәм игелекле һөнәрләрнең берсе булды һәм шулай булып кала да, чөнки без кайчандыр барыбыз да укучылар булган кешеләр. Шуңа да 11 нче сыйныфны тәмамлагач Түбән Кама педагогия училищесына укырга кердем. Башлангыч сыйныф укытучысы булу теләгем шулай тормышка ашты. Менә 23 ел инде укытучы булып балаларга хезмәт итәм.

**– Ничек уйлыйсыз, укытучы һәр балага да тигез карый аламы?**

- Укучы буларак һәрберсе дә тигез, ләкин тәртип, белем алуга омтылыш ягыннан мөнәсәббәт бөтенләй дә төрле булырга мөмкин. Һәр укучыда нинди дә булса сәләт, омтылыш бар. Моны вакытында күрә белергә һәм балага дөрес юл күрсәтергә кирәк.

***- Сез матур җырлыйсыз, бу сезнең бердәнбер хобиегызмы?***

- Җырларга кечкенәдән бик яраттым. Мәктәптә укыганда бәйрәмнәргә концерт куйганда һәрвакыт җырлый идем. Шулай ук тәмле ризыклар пешереп гаиләмне сөендерергә дә бик яратам.

**— Флүсә апа, Сезнең тормышыгызда иң бәхетле көнегез нинди?**

- Шөкер, һәр көнем бәхетле. Сау–сәламәт булуым, улымның һәм кызымның Әни дип өзелеп торулары минем өчен иң зур бәхет.

**— Газета укучыларыбызга теләкләрегез?**

- Барыгызга да чын күңелдән нык сәламәтлек, бәхет, иминлек, кызыклы иҗади идеяләр һәм, әлбәттә инде, тырыш һәм рәхмәтле укучылар телим! Киләчәктә дә укучыларыгызны белем иленә алып бару, алар алдында яңа офыклар ачу һәм үзегезгә дә шушы авыр, ләкин үтә дә кирәкле өлкәдә тагын да күбрәк үсәргә омтылу өчен бөтен нәрсәгә җитсен иде!

**Әңгәмәне Рузилә Садртдинова алып барды**

# Батырлар онытылмый

Мәктәбебездә традицион хоккей турниры быел бертуган сугышчы- интернационалистлар Нәбир, Альберт, һәм Җәмил Шәйхетдиновлар призларына үткәрелде. Турнир белән бервакытта үткәрелгән Батырлык дәресендә укучылар аларның һәркайсы белән якыннан аралышып, сөйләшер өчен мөмкинлекләр булды. “Нәрсә ул батырлык?” дигән сорауга исә җавап төрле.

- Минем өчен батырлык – яу кырыннан сугышчан дустыңны алып чыгу, - дип үз мисалын китерде Әфган сугышын кичеп, бүгенге көндә Түбән Камада яшәүче мәктәбебезнең даими кунагы һәм иганәчесе Илгиз Гыйләҗев. Ә дәрес азагында укучылар батырлыкка кайда да урын бар, моның өчен тәвәккәллек, кыюлык һәм ватанпәрвәрлек кебек сыйфатларның булуы кирәк дигән нәтиҗәгә килделәр.

Бу вакытта мәктәпнең боз мәйданчыгында сугышчы – интернационалист Шәйхетдиновларның исемнәре язылган төп трофей – Кубок өчен Фома, Чулпан, Киекле Һәм Иглай мәктәпләре командалары арасындагы көрәш кызганнан- кыза барды. Безнең хоккей командасы быел да кубокны бирәүгә дә бирмәделәр, икенче урында- Чулпан, өченчедә - Киекле командалары яулады. Гомумән, традицион чара зур оешканлык белән, мәртәбәле кунаклар катнашында, күпләгән бүләкләүләр белән үтте.






*Дускай, әйдә, бергәләшеп әниләребезгә бүләк-открытка ясыйк.*
*Журналның әлеге битен иплəп кенə кисеп алырга һəм икегə бөклəргə кирəк.*

Гөлшат
ЗӘЙНАШЕВА

# Кояш гомере

Бер кыз бала җыр чыгарган,
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк диеп,
Өйрәткән энесенә:

«Кояш, кояш
Миңге балкый,
Миңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!»

Җырны чишмәләр ишеткән,
Кошлар отып алганнар.
Сандугачлар һәм тургайлар
Матур көйгә салганнар.

Кушыл син дә,
Җырлыйк бергә,
Яңа матур җыр тусын.
Җирдә әниләр кояштай
Озын гомерле булсын.





*Открытканың битләрендә әниеңне котлап, иң матур теләк-фикерләреңне язып куй һәм төсле карандаш яисә буяу белән чәчәк бизәгән буя.*
*Уңышлар сиңа!*

*Монда әниеңнең фотосурәтен ябыштырып куй!*



Әнием!

САЛАВАТ КҮПЕРЕ
САЛАВАТ КҮПЕРЕ

# *Көлке хикмәте*



*****

-Таһир, син мине яратасыңмы?
– Яратам!
– Ә минем өчен гомереңне дә бирә алыр идеңме?
– Гомерне бирсәм, ул чагында сине кем генә ратыр соң, җаный?

****

Доктор авыруга:
- Я ничек, хәтерегез яхшырдымы?
Авыру:
- Ә син кем буласың? Нәрсә дип миңа бәйләнәсең?

****

Ике корт, тизәктән башларын чыгарып, сөйләшеп торалар ди:
- Әти, әнә тегендә бүтән кортлар алма эчендә яшиләр... Ә нигә без тизәк эчендә?
- Их, улым, аңламыйсың шул әле син... Туган җирдән газиз берни дә юк дөньяда...

* * *

Унөч яшьлек кызны әнисе тирги:
- Ах, син, юньсез кызый! Әтиең белән без сине эзләп, бөтен дискотекалар, кафелар, барлар буйлап йөгереп йөрдек! Ә син монда подъезд төбендә комлыкта уйнап утырасың икән!!

****

Әбисе белән оныгы телевизор карап утыралар, ә анда кош гриппына каршы көрәшне, йорт кошларын күпләп юк итүне күрсәтәләр. Кисәк кенә оныгы:
- Әби, ул кошларны нигә үтерәләр? - дип сорый.
- Чирләмәсеннәр өчен! - ди әбисе

****

Дингез буенда ял итүче берәү, өч көн тоташ яңгыр яуганнан соң, кайтырга җыена башлый.
- Нигә вакытыннан алда җыенасың? - дип сорый аннан күршесе.
- Мондагы яңгыр үзәккә үтте...
- Сезнең якта да шундый ук яңгыр ява лабаса.
- Аның бездәгесе очсызгарак төшә шул.

*****

Операция өстәлендә яткан авыру хирургтан сорый:
- Әйтегез әле, бу операциядән соң мин скрипкада уйный алырмынмы?
- Әлбәттә, уйный алырсыз.
- Чынмы?
- Әйе, әйе!
- Кызык кына операция икән, - дип куя авыру. - Беркайчан скрипкада уйнаганым булмады югыйсә...

**11 февраль көнне Нурлат шәһәрендә “Чаңгы юлы – 2017” массакүләм чаңгы ярышлары узды.**

Бу көнне мәктәп укучыларыннан алып, муниципаль хезмәткәрләр, җитәкче урыннарда эшләүчеләр, ветераннар да чаңгы юлына басты. Безнең мәктәп тә бу ярыштан читтә калмады. Гәрәев Фәиз, Аглиуллин Аяз кебек укучыларыбызның бу ярышта бик теләп катнашуы яшьләрнең спортка битараф булмавын күрсәтеп тора. Укытучыларыбыз: Хайруллина Л.Ю, Тарасова С.А., призлы урынга лаек булдылар. Табигать-анабыз да, кояшлы матур көн бүләк итеп, спорт сөючеләрне сөендерде.

**“Елның сыйныф җитәкчесе – 2017” конкурсы**

14 нче февральдә Нурлат районы Якушкино урта мәктәбендә “Елның сыйныф җитәкчесе” бәйгесенең беренче туры үтте. Безнең мәктәпне тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Фәхриева Гөлфия Якуп кызы** тәкъдим итте .



# Парламент дәресләре

Мәктәбебезнең өлкән сыйныф укучылары арасында “2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеш стратегиясе” темасына парламент дәресе узды. Дәрескә авыл җирлеге советы депутаты Абдрахманов Рәшит Һадиевич катнашты. Җәмгыять белеме укытучысы Гөлфия Фәхриева җитәкчелегендә укучылар тагын дистә елдан соң җөмһүриятебез һәм районыбызның киләчәгенә сәяхәт кылдылар. Ә аларның туган илләре, җирләре һәм мәктәпләрен тагын да матуррак итеп күрәсе килә. Яшь буынның фикер-тәкъдимнәренең бик әһәмиятле булуы тагын бер кат ассызыкланды.





2 нче февраль көнне районыбызда “Ел укытучысы– 2017” республика конкурсы кысаларында педагог– оештыручыларның **«Кеше тәрбияләү» һөнәри осталык** бәйгесенә сайлап алу туры узды. Районыбызда үз эшенә битараф булмаган укытучылар, һөнәрмәннәр бик күп. Бәйгедә педагог– оештыручылар мастер– класс күрсәтеләр, эш алымнары белән таныштырдылар. Иң яхшы педагог—оештыручы конкурсында безнең мәктәпнең педагог– оештыручысы **Билданова Фидалия Вазировна** 3 урынны яулады. Без аны чын күңелдән котлыйбыз һәм тагы да югарырак үрләр яулауын теләп калабыз.

## Әтиләр конференциясе

21 нче февраль көнне мәктәптә Әтиләр конференциясе булып узды. Конференция гаилә тәрбиясенең бала тормышында мөһим роль уйнавы турында барды. Укучылар һәм этиләр командасы арасында мини-КВН үтте. Бу уенда этиләрнең тәҗрибәсе, укучыларның өлгерлеге билгеләп үтелде. Әтиләрне балаларының укуы, тәрбиясе турында югары дәрәҗәдә хәбәрдар булуы күңелне сөендерде. Без этиләрне һәм мәктәбебезнең ир-егетләрен бәйрәмнәре белән котлыйбыз!









**Февраль аенда туган көннәрен бил-гeләп үтүче**

**директорыбыз**

**Сафиуллин Хәлим Салихович,**

**укытучыбыз:**

**Садртдинова Рузилә Нурисламовна**

Сезне туган көнегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкла-рыгызның күңел җылысын тоеп, игелек-ләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!





Февраль аенда туучы

кадерле укучыларыбыз:

*Гатин Илнур, Салахова Әдилә, Галимов Инсаф, Нямаева Алина, Минегулов Илсур, Гайфуллина Фидалия, Назмутдинова Энже, Шарапова Лиана, Салахова Алинә!*

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, ык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Таһирова Гайшә

**Дизайнер**: Хәйбуллина Алсу

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Гайсина Гөлшат, Садртдинова Рузилә, Ситдикова А.лсинә, Ахметова Нәзилә.